DOI: 10.26907/2311-2042-2025-25-2-135-142

# THE FAMOUS TATAR LINGUIST FAZIL SALIKHOVICH FASEEV

**Enze Khanafievna Kadirova,**
G.Ibragimov Institute of Language, Literature and Art,
Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan,
12/4 K. Marx Str., Kazan, 420111, Russian Federation,
enge@inbox.ru.



Candidate of Philology (1962) **Faseev Fazyl Salikhovich** (1925–2016) was a linguist and translator. He was a participant of the Great Patriotic War (1943–1945). After graduating from the Department of Tatar Language and Literature of the Historical and Philological Faculty at Kazan State University in 1950, he completed a postgraduate course at the Institute of Language, Literature and History. In 1952–1955, he worked in the Committee of Radio Information at the Council of Ministers of the TASSR, taught the Tatar language at the Kazan Medical and Obstetric School. In 1955–1986, he worked at the Institute of Language, Literature and History of the Kazan Branch of the USSR Academy of Sciences (in 1964–1965, he worked at Bashkir State University). F. Faseev was one of the most prominent scientists involved in the history of the Tatar literary language, the language of written monuments. The scholar's topics of interest were textual criticism, lexicology, lexicography, onomastics, etymology, etc.

**Фәсиев Фазыл Салих улы** (1925–2016) – тел белгече, тәрҗемәче. Филология фәннәре кандидаты (1962).

Бөек Ватан сугышы ветераны (1943–1945).

Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлап, 1950 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага кабул ителә.

1952–1955 елларда ТАССР МС каршындагы Радиомәгълүмат комитетында эшли, Казан фельдшер-акушерлар мәктәбендә татар теле укыта. 1955–1986 елларда СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли (1964–1965 елларда Башкорт дәүләт университетында эшләп ала). Галим татар әдәби теле тарихы, язма ядкәрләр теле һәм текстологиясе, лексикология, лексикография, ономастика, этимология һ.б. өлкәләрдә зур фәнни эшчәнлек алып бара.

**Фасеев Фазыл Салихович** (1925–2016) – языковед, переводчик. Кандидат филологических наук (1962). Участник Великой Отечественной войны (1943–1945). После окончания отделения татарского языка и литературы историко-филологического факультета Казанского государственного университета в 1950 г. был принят в аспирантуру Института языка, литературы и истории. В 1952–1955 гг. работал в комитете радиоинформации при СМ ТАССР, преподавал татарский язык в Казанской фельдшерско-акушерской школе. В 1955–1986 гг. работал в Институте языка, литературы и истории Казанского филиала АН СССР (в 1964–1965 гг. работал в Башкирском государственном университете). Ф. А. Фасеев относится к числу наиболее ярких ученых, занимавшихся историей татарского литературного языка, языка письменных памятников. Перу ученого принадлежат труды по текстологии, лексикологии, лексикографии, ономастике, этимологии и др.

**For citation:** Kadirova, E. The Famous Tatar Linguist Fazil Salikhovich Faseev // Tatarica. 2025. № 2 (25). pp. 135–142. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-135-142

**Сылтама өчен:** Кадирова Э. Х. Күренекле тел галиме Фазыл Салих улы Фәсиев // Tatarica. 2025. № 2 (25). 135–142 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-135-142

**Для цитирования**: Кадирова Э. Х. Известный татарский языковед Фазыл Салихович Фасеев // Tatarica. 2025. № 2 (25). С. 135–142. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-135-142

Fazyl Faseev was born on October 18, 1925, in the village of Aseevo (Esei) in the Aznakaevsky District of the TASSR. However, his father Salikh, who worked as a teacher, had to return to his homeland – to the newly formed Shugurovsky (Shoger) District – to participate in economic and party work (to organize the work of the district newspaper “A Collective Farm” (“Totash kolkhoz”), to set up a printing house and an editorial office, to teach in schools, etc.). The family settled first in the village of Timyashevo (Timesh) in the present-day Leninogorsk District, then in the village of Staroe Shugurovo (Iske Shoger) where Fazyl’s father, Salikh Fatykhovich, (05.02.1903–1984) and his mother, Zainap Kashapova (born in 1910), worked. So, the young man received his secondary education at the Staro Shugurovskoe secondary school. After the start of the war, during the vacations and the summer holidays, before being drafted for military service, he worked at the collective farm “Centre” (“Uzek”) and the MTS (a machine and tractor station). On January 16, 1943, he was drafted into the army and until June of the same year was a cadet at the Zhytomyr Military Infantry School stationed in Kazan. Private Fazyl Faseev was a rifleman of the 10th Guards Airborne Brigade, and from February 1944, he was a rifleman of the 301st Kutuzov Order Guards Rifle Regiment of the 100th Infantry Division. From June 20 to June 27, 1944, he participated in the Svir military operation at the Karelian Front where he was seriously wounded in his right leg on June 27 and was treated in a hospital until June 1945. In August of the same year, he was discharged from the army. He was awarded many medals and became a Knight of the Order of the Patriotic War (II degree) (1985). Fazyl’s father, Salikh Faseev, also participated in the war. In 1942–1945, as a senior lieutenant, Salikh fought in the 930th Infantry Regiment and the 82nd Separate Tank Regiment. Another of Fazyl’s paternal brothers, Munir, served in the military from 1938 to 1964, rising to the rank of lieutenant colonel-engineer. His brother, Sharif, the chief doctor of the regiment, a graduate of the Military Medical Academy, went missing in action near Rostov-on-Don in 1942.

The pedigree of F. Faseev goes back to the famous writer, theologian, philosopher, Gabdrakhim Utyz-Imyani [1, 2, 3]. He was a descendant of educated people (Fatih’s three sons – the brothers Salikh, Munir, and Kamil – received a degree in teaching; later Salikh became the director of the Staro Shugurovskoe School, an honoured teacher of the Republic of Tatarstan; Munir was a candidate of philosophy, he held the position of associate professor at the Civil Engineering Institute, and Kamil Faseev was a professor at Kazan State University named after V. I. Ulyanov-Lenin) [4].

The successor of the family, associated with teaching, Fazyl Faseev, entered the Department of Tatar Language and Literature of the Historical and Philological Faculty at Kazan State University in 1945. Upon graduation, he completed a postgraduate course of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and History. From September 1955 to 1986 (in 1964–1965 he worked at the Department of Tatar Philology of Bashkir State University as an associate professor), he worked his way up from a senior laboratory assistant to a senior researcher at the Institute of Language, Literature and History of the Kazan Branch of the USSR Academy of Sciences. In 1961, Fazyl Salikhovich defended his Ph.D. thesis devoted to “The Methods of Term Formation in the Tatar Literary Language” [5].

F. Faseev’s research work started as a lexicographer. In 1958, his “Lexicological questionnaire for Collecting Words for Compiling an Explanatory Dictionary of the Tatar Language” (“Tatar telenen anlatmaly suzlegen tozuge suzler zhyiu ochen liksikologik sorawlyk”) was published [6]. This work is structured in such a way that it allows you to combine the entire lexical wealth of the Tatar language into a single whole. This is evidenced by the fact that it is still used as a basis for grouping the vocabulary of other Turkic languages [7].

F. Faseev participated in the compilation of "The Tatar-Russian Dictionary". In parallel with compiling the dictionary, he wrote a "Short Guide to the Tatar Language". In it, the scholar provided detailed information about the phonetics, graphics, morphology and syntax of the Tatar language, giving an overview of the Tatar dialects, and introduced the history of the Tatar language. In each case, he concretised the theory with practical examples [8].

Fazyl Faseev was a versatile personality in science. His works relate to terminology, the history of the Tatar language, textual criticism, lexicography, etymology, and historical onomastics.

In 1969, F. Faseev's monograph "Fundamentals of Terminology of the Tatar Language" ("Tatar tele terminologiyese nigezlere") was published [9]. The book became a big novelty of that time in the study of terms. To this day, this work of the scholar remains a very sought-after reference book for specialists in many fields, as it is rich in content and based on a wealth of factual material. At the same time, the book includes a deep historical analysis of the terms' development.

In 1982, another monograph of the scientist was published. The work "Old Tatar Business Writing of the 18th Century" contains various documents, letters and orders of the Peasant War, led by Pugachev in 1773–1775. Some of these 73 documents were taken from published sources, but the majority were introduced into scientific circulation for the first time, after the author had found them in the archives. The scholar gave the texts, written in Arabic script, in the Old Tatar language, in Cyrillic and translated them into Russian. Each text was fully analysed, and detailed notes were provided [10].

However, to the general public, the scholar F. Faseev became known thanks to Kul Gali's book "Kissai Yusuf" ("The Legend of Yusuf") [11]. Fazil aga noted that "Kissai Yusuf" "was an educational book used in schools: Bulgarian-Tatar children, as soon as they learned letters, learned the book by heart; and madrasah students, along with learning lessons in beautiful writing and stylistics, considered it a righteous deed to copy this kissai for themselves or others; and those who were engaged in creative work composed their first bayts and wrote letters in poetry to their loved ones based on the examples from the book about Yusuf [12]. The scholar recorded a list of manuscripts (161 copies), stored in different countries and different places, examined printed copies of the book, providing detailed information about them. He collected numerous copies of the poem, their photocopies and, after carefully studying them, gave a transcription of their texts from Arabic script to Cyrillic. He wrote the preface, translated it into the modern Tatar literary language, enriched it with notes and published a translation into Russian, made jointly with his wife, Almaziya Nurieva, a well-known linguist and lecturer at Kazan State University. The scientific result of this work, which lasted for 15 years, was the publication of a large book "Kissai Yusuf" by the 13th century Tatar poet Kul Gali (its volume of about 60 sheets, the circulation – 10 thousand copies) [11].

Fazyl abyi did a lot of work together with his wife, Almaziya Khazievna. Their joint work, "The Spelling Dictionary of the Tatar Language" ("Tatar telenen orfografik suzlege"), has been repeatedly republished and has become a reference book for thousands of students [13]. F. Faseev, together with A. Nurieva, developed textbooks and study guides for Tatar schools [14; 15].

Numerous articles by the scholar, covering certain issues of the history of our language, were published in the collections of research papers of the Institute and in periodicals [16; 17; 18; 19; 20; 21; 22, etc]. Each of these articles discusses the most important, and interesting questions of the Tatar language, and provides answers to difficult questions. These works are still being read, studied and used in research work by scholars working in many fields of science.

The scholar also worked as a scientific editor. He is known as the compiler and editor of the 4-volume Russian-Tatar dictionary, published in 1955–1959. R. Gazizov's work "Comparative Grammar of the Tatar and Russian Languages" was published under the scientific editorship of F. Faseev [23]. Fazyl aga Faseev performed the bulk of the work on the compilation and preparation for publication of the book "Historical Morphology of the Tatar Language (Essays)" ("Tatar telenen tarikhi morfologiyese") by the outstanding Tatar scientist Prof. Latif Jalai, the work based on the manuscripts of lectures on the history of the language for university students. This work, devoted to the historical study of the grammatical structure (morphology) of our language, was published as a special book in 2000 [24]. This list could be continued [25, 26].

Under the supervision of F. Faseev, Marsel Akhmetzyanov defended his Ph.D. "The Study of Tatar Shezhere in the Source and Linguistic Aspects (according to the copies of the 19th –20th

centuries)" [27]. In one of his interviews, he remembers Fazil Salikhovich very warmly, and the memories of joint expeditions with his supervisor are invaluable to him. He notes that Faseev was a good expedition organizer and a very humane and caring mentor: Once, when sitting and talking with an old man, I did not notice that night had fallen. This man said, "Stay the night!" I did as he had offered. Fazyl abyi was terrified, worried all night, asking where I could be [28].

The people of Shugurov do not forget the glorious sons of this family. They write about Fazyl aga and his relatives in works on the history of the region [29, 30].

Fazyl aga Faseev was a man of a big heart, straightforward, deeply educated, eager for knowledge, self-demanding, honest, and humane. With his works, the scholar Fazyl Faseev made a huge contribution to the development of Tatar and Turkic linguistics.

**References**

1. *Kazanskaya lingvisticheskaya shkola* (2008). [Kazan Linguistic School]. Kniga pervaya: Kazanskaya tyurkskaya lingvisticheskaya shkola. 424 p. Sost. M. Z. Zakiev. Kazan', Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

2. Camaletdİnov, R., Camaletdİnova, G. (2019). *Fazil Salİhovİç Faseyev* [Fazyl Salikhovich Faseev]. Türkİye dişindakİ türk dünyasi türkologlari 2. cİlt. Dİlcİler. Ed. Prof. Dr. A. Buran. Pp. 1047-1051. Akçağ. (In Turkish)

3. *Sokhranyaya traditsii, dumaya o budushchem: istoriya IYALI im. G. Ibragimova v litsakh* (2024) [Preserving Traditions, Thinking about the Future: The History of the Ibragimov Institute of Language, Literature and History in Faces]. Redkollegiya K. M. Minnullin (rukovoditel'), L. M. Giniyatullina, L. Sh. Galieva, E. Kh. Kadirova, M. Z. Valieva. 204 p. Kazan'. (In Russian)

4. *Ideologii ne "seryi kardinal"* (2021) [Not "the Gray Cardinal" of Ideology]. Samara tatarlary = Samarskie tatary. 24 avg. (In Russian)

5. Faseev, F. S. (1961). *Sposoby obrazovaniya terminov v tatarskom literaturnom yazyke: avtoref. dis. ... kand. filol. nauk* [Methods of Forming Terms in the Tatar Literary Language: Ph.D. Thesis Abstract]. Moscow, 40 p. (In Russian)

6. Faseev, F. (1958). *Tatar teleneң aңlatmaly syzlegen təzygə syzlər җyyu өchen leksikologik soraulyk* [Lexicological Questionnaire for Collecting Words for Compiling an Explanatory Dictionary of the Tatar Language]. 105 p. Kazan'. (In Tatar)

7. Shaikhulov, A. G. (1983). *Nekotorye voprosy sistemnogo issledovaniya apellyativny kh i toponimicheskikh edinits (na materiale yazykov Uralo-Povolzh'ya)* [Some Issues of Systemic Research of Appellative and Toponymic Units (based on the languages of the Ural-Volga Region)]. Voprosy onomastiki. Sverdlovsk, URGU. Vyp. 16, pp. 35–41. Metody toponimicheskikh issledovanii. (In Russian)

8. Faseev, F. S. (1966). *Kratkii grammaticheskii spravochnik tatarskogo yazyka* [A Brief Grammar Guide to the Tatar Language]. Tatarsko-russkii slovar'. Pp. 809–813. Moscow, "Sovetskaya ehntsiklopediya". (In Russian)

9. Faseev, F. S. (1969). *Tatar telendə terminologiya nigezləre* [Fundamentals of Terminology of the Tatar Language]. 200 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

10. Faseev, F. S. (1982). *Starotatarskaya delovaya pis'mennost' XVIII v.* [Old Tatar Business Writing of the 18th Century]. Kazan', Tat. kn. izd-vo. (In Russian)

11. Kol Gali (1983). *Kyissai Iosyf* [The Legend of Yusuf]. Təp tekstny əzerləүche keresh məkaləne, iskərmə həm kul"yazmalarnyң tasvirlamalaryn yazuchy F. S. Fasiev. 543 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

12. Fəsiev, F. S. (1988). *Kyissai Iosyf həm anyң avtory turynda* [About Kissai Yusuf and Its Author]. Kazan utlary. No. 3. (In Tatar)

13. *Tatar teleneң orfografik syzlege* (1983) [Spelling Dictionary of the Tatar Language]. Tөz. A. Kh. Nurieva, F. S. Faseev, M. I. Məkhmүtov. 279 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

14. Nurieva, A. Kh., Faseev, F. S. (1966). *Ana tele buencha məstəkyil' ehshlər: 5–6 klasslar өchen kartochkalar həm kyzykly tel belemennən materiallar* [Independent Work in the Native Language: Flashcards and Interesting Materials on Linguistics for Grades 5–6]. 237 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

15. Faseev, F. S., Nurieva, A. Kh. (1984). *Tatar telennehn didaktik materiallar: 4 kl.: ukytuchyga kullanma* [Didactic Materials on the Tatar Language: 4th Grade: A Teacher's Manual]. 2 nche basma. 46 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

16. Faseev, F. S. (1960). *Interesnoe foneticheskoe yavlenie v tatarskikh dialektakh* [An Interesting Phonetic Phenomenon in Tatar Dialects]. Voprosy dialektologii tyurkskikh yazykov. Pp. 145–149. Baku. (In Russian)

17. Faseev, F. S. (1969). *Opyt sravnitel'no-statisticheskogo issledovaniya leksiki tatarskogo yazyka (stat'ya pervaya)* [An Experience of a Comparative Statistical Study of the Vocabulary of the Tatar Language (Article One)]. Voprosy tatarskogo yazyka i literatury. Kn. IV, pp. 41–54. Kazan'. (In Russian)

18. Faseev, F. S. (1978). *Kto oni tak nazyvaemye "golubye tyurki"?* [Who Are These So-called "Blue Turks"?]. Istochnikovedenie i istoriya tyurkskikh yazykov. Pp. 137–147. Kazan'. (In Russian)

19. Faseev, F. S. (1978). *K rasshifrovke khunnskikh fragmentov (Altaica-turcica)* [On the Decipherment of Xiongnu Fragments (Altaica-turcica)]. Istochnikovedenie i istoriya tyurkskikh yazykov. Pp. 124–136. Kazan'. (In Russian)

20. Faseev, F. S. (1982). *Nekotorye problemy istochnikovedeniya i istoriografii istorii tatarskogo yazyka* [Some Problems of Source Studies and Historiography of the History of the Tatar Language].

Issledovaniya po dialektologii i istorii tatarskogo yazyka. Pp. 78–98. Kazan'. (In Russian)

21. Faseev, F. S. (1983). *Nekotorye utochneniya ehtimologii* [Some Clarifications of Etymologies]. Istoriko-lingvisticheskii analiz staropismennykh pamyatnikov. Pp. 107–120. Kazan'. (In Russian)

22. Faseev, F. S. (1985). *Vokalizm tatarskogo yazyka v sinkhronii i diakhronii* [Vocalism of the Tatar Language in Synchrony and Diachrony]. K formirovaniyu yazyka tatar Povolzh'ya i Priural'ya. Pp. 99–109. Kazan'. (In Russian)

23. Gazizov, R. S. (1966). *Sopostavitel'naya grammatika tatarskogo i russkogo yazykov* [Comparative Grammar of the Tatar and Russian Languages]. Pod red. kand. filol. nauk F. S. Faseeva. Pererab. i dop. izd. 368 p. Kazan', Tatknigoizdat. (In Russian)

24. Җәләi, L. (2000). *Tatar teleneң tarikhi morfologiyase (ocherklar)* [Historical Morphology of the Tatar Language (Essays)]. 287 p. Kazan, Fiker. (In Tatar)

25. *Ruscha-tatarcha avyl khuҗalygy terminnary syzlege* (1971) [Russian-Tatar Agricultural Dictionary]. Red. F. S. Faseev; tөz. A. K. Timergalin; G. G. Akhmetov; Sh. G. Sadyikov. 303 p. Kazan, Tatar. kit. nәshr. (In Tatar)

26. Fәtkhiev, A. S. (1986). *Tatar әdiplәre hәm galimnәreneң kul"yazmalary: KDU Fәnni kitapkhanәsenә 1959–1969 ellarda kergәn kul"yazmalarynyң tasvirlamasy* [Manuscripts of Tatar Writers and Scholars: A Description of the Manuscripts Received by the Scientific Library of Kazan State University in 1959–1969]. F. red. F. S. Faseev. 162 p. Kazan, Kazan universitety nәshriyaty. (In Tatar)

27. Akhmetzyanov, M. I. (1981). *Issledovanie tatarskikh shedzhere v istochnikovedcheskom i lingvisticheskom aspektakh (po spiskam XIX-XX vv.): avtoref. dis. ... kand. filol. nauk* [The Study of Tatar Shezhere in the Source and Linguistic Aspects (according to the copies of the 19th–20th centuries): Ph.D. Thesis Abstract]. Alma-Ata, 25 p. (In Russian)

28. Әkhmәtҗanov, M. I. (2019). *Sailanma khezmәtlәr* [Selected Works]. 336 p. Kazan, TӘhSI. (In Tatar)

29. *Shugur – krai sokrovishch = Shөger tөbәge – khәzinәlәr chishmәse* (1997) [Shugur – the Land of Treasures]. Z. Rakhimov. 266 p. Kazan', Star. (In Tatar)

30. Rәkhimev, Җ. (2008). *Sailanma әsәrlәr* [Selected Works]. 1 tom: Avyllar tarikhy. Khikәyalәr hәm publitsistika. 444 p. Kazan, Rukhiyat. (In Tatar)

---

# КҮРЕНЕКЛЕ ТЕЛ ГАЛИМЕ ФАЗЫЛ САЛИХ УЛЫ ФӘСИЕВ

**Энҗе Хәнәфи кызы Кадирова,**
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,
Россия, 421111, Казан ш., К. Маркс ур., 12/4 нче йорт,
enge@inbox.ru.

Фазыл Салих улы Фәсиев 1925 елның 18 октябрендә ТАССР ның Азнакай районы Әсәй авылында туа. Әмма укытучы булып эшләгән этисе Салих Фатыйх улына хуҗалык-партия эшләрендә катнашу («Тоташ колхоз» район газетасын оештыру; типография һәм редакция эшен, мәктәпләрдә укытуны җайга салу һ.б.ш.) өчен, туган ягына – ул вакытта яңа оешып килә торган Шөгер районына кайтырга туры килә. Гаилә, башта хәзерге Лениногорск районындагы нигезләре Тимәш авылына, аннан гаилә башлыгы Салих Фатыйх улының (05.02.1903-1984) һәм әниләре Зәйнәп Кәшапованың (1910 елда туган) эш урыны булган Иске Шөгер авылына урнаша. Шулай итеп егеткә урта белемне Иске Шөгер урта мәктәбендә алырга насыйп була. Сугыш башлангач, Фазыл каникул вакытларында, җәйге ялларында, хәрби хезмәткә чакыру килгәнче авылларындагы «Үзәк» колхозында, МТСта эшли. 1943 елның 16 гыйнварында ул армиягә алына һәм шул елның июненә кадәр, Казан шәһәренә килеп урнашкан Житомир хәрби-пехота училищесының курсанты була. Рядовой Фазыл Салих улы 10 нчы гвардия һава-десант бригадасы укчысы, 1944 елның февраленнән 100 укчы дивизиянең 301 нче Кутузов орденлы гвардия укчы полкы укчысы була. 1944 елның 20–27 июнендә Карелия фронтындагы Свирск хәрби операциясендә катнаша, шунда 27 июнь көнне уң аягына каты яралана һәм 1945 елның июненә кадәр госпитальдә дәвалана. Шул елның августында армия сафларыннан демоблизацияләнә. Ул II дәрәҗә Ватан сугышы ордены (1985) кавалеры, күп кенә медальләр белән бүләкләнә. Фазылның этисе Салих Фатыйх улы шулай ук хәрби хәрәкәтләрдә катнаша. Өлкән лейтенант дәрәҗәсендәге Салих 1942-1945 елларда 930 нчы укчы полк, 82 нче аерым танк полклары составында сугыша. Фазылның этисе ягыннан тагын бер абыйсы Мөнир Фатыйх улы 1938

елдан 1964 елга кадәр хәрби хезмәттә булып, подполковник-инженер дәрәҗәсенә күтәрелә. Бертуганнары Хәрби-медицина академиясен тәмамлаган полк баш врачы Шәриф Фатыйх улы 1942 елда Ростов-на-Дону тирәсендә барган сугышларда хәбәрсез югала .

Ф. Фәсиевнең нәсел җепләре атаклы язучы, дин белгече, фәлсәфәче Габдерәхим Утыз Имәнигә барып тоташа [1; 2; 3]. Укымышлы нәсел дәвамчысы (Фатыйхның өч улы бертуган Салих, Мөнир, Камил педагог белгечлеге алалар, соңыннан Салих – Иске Шөгер мәктәбе директоры, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы; Мөнир – фәлсәфә фәннәре кандидаты, төзелеш институтында доцент вазифасын башкара, ә Камил Фәсиев – В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты профессоры) [4].

Укытучылык эшчәнлеге белән бәйле нәсел дәвамчысы Фазыл Фәсиев 1945 елда Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң, ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантурада белем ала. 1955 елның сентябреннән 1986 елга кадәр (1964–1965 елларда Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасында доцент вазифасында эшләп ала) СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән лаборанттан өлкән фәнни хезмәткәргә кадәр хезмәт юлы үтә. Фазыл Салих улы 1961 елда «Татар әдәби телендә терминнар ясау ысуллары (Способы образования терминов в татарском литературном языке)» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый [5].

Ф. Фәсиев фәнни эшчәнлеген лексикограф буларак башлый. 1958 елда аның «Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүгә сүзләр җыю өчен лексикологик сораулыг»ы басыла [6]. Бу хезмәт татар теленең бөтен лексик байлыгынербөтен итеп җыярга мөмкинлек бирә торган итеп төзелгән. Хәзерге вакытта да аны башка төрки телләрнең дә сүз байлыгын төркемнәргә бүлүдә нигез итеп алулары шул хакта сөйли [7].

Ф. Фәсиев «Татарча-русча сүзлек»не төзүдә катнаша. Ул сүзлек төзү белән беррәттән, китап өчен «Татар теленә карата кыскача белешмә»не яза. Анда галим татар теле фонетикасы, графикасы, морфологиясе, синтаксисы турында тулы мәгълүмат китерә, татар диалектларына күзәтү ясый, татар теле тарихы белән таныштыра. Ул һәр очракта теоретик мәсьәләләрне төгәл мисаллар белән раслый [8].

Фазыл Салихович Фәсиев фәндә киңкырлы шәхес иде. Аның хезмәтләре терминологиягә, татар теле тарихына, текстологиягә, лексикографиягә, этимологиягә, тарихи ономастикага кагыла.

1969 елда Ф. Фәсиевнең «Татар теле терминологиясе нигезләре (Основы терминологии татарского языка)» монографиясе басыла [9]. Китап терминнарны өйрәнүдә шул чорның зур яңалыгы була. Галимнең бу хезмәте бүгенге көнгә кадәр күп өлкәдәге белгечләр өчен бик кирәкле белешмә булып кала, чөнки ул бай эчтәлекле, күп фактик материалга нигезләнеп язылган. Шул ук вакытта терминнар үсешенә тарихи планда тирән анализ ясалган.

1982 елда галимнең тагын бер монографиясе дөнья күрә. «Старотатарская деловая письменность XVIII века» хезмәтендә 1773–1775 еллардагы Пугачёв җитәкчелегендәге крестьяннар сугышының төрле документлары, хатлары һәм өндәмәләре тупланган. Әлеге 73 документның кайберләре берничә бастырылган чыганактан алынган булса, зур өлешен автор, архивларда эзләнеп, беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертә. Галим гарәп графикасындагы иске татар телендә язылган текстларны кириллицада бирә һәм рус теленә тәрҗемә итә. Һәр текст тулы анализланган, җентекле искәрмәләр китерелгән [10].

Шулай да киң җәмәгатьчелеккә күренекле галим Ф. Фәсиев Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабы аша билгеле [11]. Фазыл ага билгеләп үткәнчә, «Кыйссаи Йосыф» «мәктәпләрдә уку китабы булып йөргән, болгар-татар баласы, хәреф тану белән үк, аны укып ятлаган, мәдрәсә шәкертләре исә хосне хат (матур язу һәм стилистика) дәресләрен үзләштергән. Кыйссаны үзенә күчереп алу яки бүтәннәргә күчереп бирүне күңел һәм савап эше дип хисаплаганнар, «Йосыф китабы үрнәгендә беренче бәетләрен чыгарганнар, беренче тезмәләрен язып мәгъшукаларына хат итеп күндергәннәр [12]. Галим бу язма истәлекнең төрле илләрдә, төрле җирләрдә сакланган кульъязмалар исемлеген (161 данә) терки, басма нөсхәләрне барлый, алар турында тулы мәгълүмат китерә. Ул поэманың күпсанлы нөсхәләрен, аларның фотокопияләрен туплый һәм аларны ныклап өйрәнеп, текстның гарәп шрифтыннан кириллицага транскрипциясен бирә. кереш сүз яза, хәзерге татар әдәби теленә күчермәсен китерә, искәрмәләр белән баета һәм

хатыны, күренекле тел галимәсе, Казан дәүләт университеты мөгаллимәсе Алмазия Хаҗи кызы Нуриева белән берлектә ясалган рус теленә тәрҗемәсе урын ала. 15 елга сузылган бу эшнең фәнни нәтиҗәсе буларак, XIII йөз татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре зур, матур китап булып (күләме 60 табак чамасы, тиражы – 10 мең данә) дөнья күрә [11].

Фазыл абыйның хатыны Алмазия Хазиевна белән берлектә эшләгән хезмәтләре шактый. Берничә тапкыр басылган, меңләгән укучы өчен өстәл китабы булган «Татар теленең орфографик сүзлеге» – аларның уртак хезмәте [13]. Ф. Фәсиев А. Нуриева белән берлектә татар мәктәпләре өчен дәреслекләр, кулланмалар эшләделәр [14; 15].

Галимнең телебез тарихының аерым мәсьәләләрен яктырткан күпсанлы мәкаләләре институт җыентыкларында, вакытлы матбугат битләрендә дөнья күрде [16; 17; 18; 19; 20; 21; 22 һ. б.]. Саналган мәкаләләрнең кайсын гына алсаң да, аларда татар теленең иң әһәмиятле, мөһим, кирәкле, һәркем өчен кызыклы мәсьәләләре карала, четерекле сорауларга җаваплар урын ала. Бу хезмәтләрне бүген дә фәннең күп өлкәләрендә хезмәт куючы галимнәр укыйлар, өйрәнәләр, elibrary күрсәткәнчә, фәнни эшләрендә кулланалар.

Галим фәнни редактор буларак та хезмәт куя. Ул 1955–1959 елларда басылган 4 томлык русча-татарча сүзлекнең төзүчесе һәм редакторы буларак билгеле. Р.С. Газизовның «Сопоставительная грамматика татарского и русского языков» хезмәте дә Ф.С. Фәсиевнең фәнни редакциясендә басыла [23]. Күренекле татар галиме профессор Латыйф Җәләйнең университет студентларына тел тарихыннан укыган лекцияләренең кулъязмаларына нигезләнгән «Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар)» китабын төзүдә һәм матбугатка әзерләүдә төп эшне Фазыл ага Фәсиев башкара. Телебезнең грамматик төзелешен (морфологиясен) тарихи юнәлештә өйрәнүгә багышланган бу хезмәт махсус китап рәвешендә 2000 елда басылып чыга [24]. Бу исемлекне тагын дәвам итеп булыр иде [25; 26].

Ф. Фәсиев җитәкчелегендә Марсель Әхмәтҗанов «Исследование татарских шеджере в источниковедческом и лингвистическом аспектах (по спискам XIX-XX вв.)» темасына кандидатлык диссертациясе язып яклый [27]. Укучысы үзенең бер интервьюсында Фазыл Салих улын бик җылы искә ала, җитәкчесе белән булган уртак экспедицияләр аның өчен бәяләп бетергесез истәлек булып кала. Ул аның экспедицияләрдә яхшы оештыручы һәм дә кешелекле, кайгыртучан остаз булуын ассызыклый: Бер бабайда утыра торгач, төн җиткәнен сизми калганбыз. Бабай әйтә: «Кунып кына кал инде!» – ди. Калдым. Фазыл абыйның коты алынган, төн буе кайгырып яткан, кая микән бу дип [28].

Шөгер халкы бу нәселнең данлыклы улларын онытмый. Фазыл ага, аның туганнары турында төбәк тарихына багышланган хезмәтләрдә язалар, исемнәрен атыйлар [29; 30].

Фазыл ага Фәсиев олы җанлы, туры сүзле, тирән белемле, эзләнүчән, үзенә таләпчән, намуслы, кешелекле галим иде. Галим Фазыл Салих улы Фәсиев хезмәтләре белән татар тел белемен һәм төрки тел белемен үстерүгә үзеннән гаять зур өлеш кертте.

**Әдәбият**


1. Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа / Сост. М.З. Закиев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. 424 с.

2. *Camaletdİnov R., Camaletdİnova G.* Fazil Salİhovİç Faseyev // Türkİye dişindakİ türk dünyasi türkologlari 2. cİlt. Dİlcİler / ED. Prof. Dr. A. Buran. Akçağ, 2019. s. 1047-1051

3. Сохраняя традиции, думая о будущем: история ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова в лицах / Редколлегия К.М. Миннуллин (руководитель), Л.М. Гиниятуллина, Л.Ш. Галиева, Э.Х. Кадирова, М.З. Валиева. Казань, 2024. 204 с.

4. Идеологии не «серый кардинал» // Самара татарлары = Самарские татары. 2021. 24 авг.

5. *Фасеев Ф.С.* Способы образования терминов в татарском литературном языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Москва, 1961. 40 с.

6. *Фасеев Ф.* Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүгә сүзләр җыю өчен лексикологик сораулык. Казань, 1958. 105 б.

7. *Шайхулов А.Г.* Некоторые вопросы системного исследования апеллятивных и топонимических единиц (на материале языков Урало-Поволжья) // Вопросы ономастики. Свердловск: УрГУ, 1983. Вып. 16. Методы топонимических исследований. С. 35-41.

8. *Фасеев Ф.С.* Краткий грамматический справочник татарского языка // Татарско-русский словарь. Москва: «Советская энциклопедия», 1966. С. 809-813.

9. *Фасеев Ф.С.* Татар телендә терминология нигезләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 200 б.

10. *Фасеев Ф.С.* Старотатарская деловая письменность XVIII в. Казань: Тат. кн. изд-во, 1982.

11. *Кол Гали* Кыйссаи Йосыф / Төп текстны әзерләүче кереш мәкаләне, искәрмә һәм

кульязмаларның тасвирламаларын язучы Ф.С. Фасиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 543 б.

12. *Фәсиев Ф.С.* Кыйссаи Йосыф һәм аның авторы турында // Казан утлары. 1988. №3.

13. Татар теленең орфографик сүзлеге / [төз. А.Х. Нуриева, Ф.С. Фасеев, М.И. Мәхмүтов]. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 279 б.

14. *Нуриева А.Х., Фасеев Ф.С.* Ана теле буенча мөстәкыйль эшләр: 5-6 класслар өчен карточкалар һәм кызыклы тел белеменнән материаллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. 237 б.

15. *Фасеев Ф.С., Нуриева А.Х.* Татар теленнән дидактик материаллар: 4 кл.: укытучыга кулланма. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 46 б.

16. *Фасеев Ф.С.* Интересное фонетическое явление в татарских диалектах // Вопросы диалектологии тюркских языков. Баку, 1960. С. 145-149.

17. *Фасеев Ф.С.* Опыт сравнительно-статистического исследования лексики татарского языка (статья первая) // Вопросы татарского языка и литературы. Кн.IV. Казань, 1969. С.41-54.

18. *Фасеев Ф.С.* Кто они так называемые «голубые тюрки»? // Источниковедение и история тюркских языков. Казань, 1978, С. 137-147.

19. *Фасеев Ф.С.* К расшифровке хуннских фрагментов (Altaica-turcica) // Источниковедение и история тюркских языков. Казань, 1978. С. 124-136

20. *Фасеев Ф.С.* Некоторые проблемы источниковедения и историографии истории татарского языка» // Исследования по диалектологии и истории татарского языка. Казань, 1982. С.78-98.

21. *Фасеев Ф.С.* Некоторые уточнения этимологий // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. Казань, 1983. С. 107-120.

22. *Фасеев Ф.С.* Вокализм татарского языка в синхронии и диахронии // К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. Казань, 1985. С. 99-109.

23. *Газизов Р.С.* Сопоставительная грамматика татарского и русского языков / Под ред. канд. филол. наук Ф.С. Фасеева. Перераб. и доп. изд. Казань: Таткнигоиздат, 1966. 368 с.

24. *Җәләй Л.* Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар). Казан: Фикер, 2000. 287 б.

25. Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге / ред. Ф.С. Фасеев; төз. А.К. Тимергалин; Г.Г. Ахметов; Ш.Г. Садыйков. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 303 б.

26. *Фәтхиев А.С.* Татар әдипләре һәм галимнәренең кульязмалары: КДУ Фәнни китапханәсенә 1959-1969 елларда кергән кульязмаларының тасвирламасы [ф. ред. Ф.С. Фасеев]. Казан: Казан университеты нәшрияты, 1986. 162 б.

27. *Ахметзянов М.И.* Исследование татарских шеджере в источниковедческом и лингвистическом аспектах (по спискам XIX-XX вв.): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Алма-Ата, 1981. 25 с.

28. *Әхмәтҗанов М.И.* Сайланма хезмәтләр. Казан: ТӘһСИ, 2019. 336 б.

29. Шугур – край сокровищ = Шөгер төбәге – хәзинәләр чишмәсе / З. Рахимов. Казань: Стар, 1997. 266 с.

30. *Рәхимев Җ.* Сайланма әсәрләр. 1 том: Авыллар тарихы. Хикәяләр һәм публицистика. Казан: Рухият, 2008. 444 б.